ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» апрель 2026 ел № 293

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге Муниципаль берәмлеге милкендәге каты көнкүреш калдыклары полигоны составына керүче объектларга карата “Яңа Кенәр коммуналь хезмәтләре” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең концессия килешүен төзү инициаторы тәкъдим иткәннән башка шартларда концессия килешүе төзү мөмкинлеге турында**

“Концессия килешүләре турында” 2005 елның 21 июлендәге 115 номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 4.8 өлеше нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Концессия килешүе төзүгә конкурста катнашуга әзерлек турында гариза формасын раслау һәм концессия килешүе төзү инициативасы белән чыгыш ясаучы зат белән концессия килешүе төзү турында тәкъдим формасына үзгәрешләр кертү хакында” 2023 елның 16 сентябрендәге 1515 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге милкендәге каты көнкүреш калдыклары полигоны составына керүче объектларга карата концессия килешүе төзү турында “Яңа Кенәр коммуналь хезмәтләре” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тәкъдиме белән, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кенәр авыл җирлеге Муниципаль берәмлеге милкендәге каты көнкүреш калдыклары полигоны составына керүче объектларга карата “Яңа Кенәр коммуналь хезмәтләре” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең концессия килешүен төзү инициаторы тәкъдим иткәннән башка шартларда концессия килешүе төзү мөмкинлеге турында карар кабул итәргә

2. Концессия килешүе төзү инициаторы тәкъдим иткәннән башка шартларда концессия килешүе төзү мөмкинлеге турында карар кабул итүгә бәйле рәвештә концессия килешүе шартларын килештерү максатларында сөйләшүләр уздыруның кушымтада бирелә торган Тәртибен (алга таба - Тәртип) расларга (1 нче кушымта).

3. “Яңа Кенәр коммуналь хезмәтләре” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән уртак киңәшмәләр рәвешендә сөйләшүләр алып баруга вәкаләтле эшче төркем төзергә һәм аның составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Күрсәтелгән эшче төркемгә әлеге карарга кул куелган көннән алып 10 (ун) эш көне эчендә концессия килешүе шартлары һәм аларны килештерү Тәртибе нигезендә килештерү максатларында “Яңа Кенәр коммуналь хезмәтләре” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән уртак киңәшмәләр рәвешендә сөйләшүләр уздырырга.

5. Концессия килешүен башка шартларда төзү мөмкинлеге турында “Яңа Кенәр коммуналь хезмәтләре” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә хәбәр итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында https://arsk.tatarstan.ru һәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә.

7. Әлеге карар аңа имза салынган көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе И. Г. Сиражиевка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.И.Абдуллин

**Арча муниципаль районы башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта**
**«10» апрель 2026 ел № 283**

**Концессия килешүе төзү инициаторы тәкъдим иткәннән башка шартларда концессия килешүе төзү мөмкинлеге турында карар кабул итүгә бәйле рәвештә концессия килешүе шартларын килештерү максатларында сөйләшүләр үткәрү тәртибе**

1. Килешү төзү инициаторы тәкъдим иткәннән башка шартларда килешү төзү мөмкинлеге турында карар кабул итүгә бәйле рәвештә концессия Килешүе (алга таба - Килешү) шартларын килештерү максатларында сөйләшүләр Килешү төзү инициаторының вәкаләтле вәкилләре катнашында эшче төркемнең уртак киңәшмәләре рәвешендә уздырыла (алга таба - сөйләшүләр).

2. Килешү төзү инициаторы тәкъдим иткәнгә караганда башка шартларны килештерү турындагы карар эшче төркем тарафыннан кабул ителә һәм беркетмә рәсмиләштерелә, ул сөйләшүләрдә катнашкан барлык затлар тарафыннан имзалана.

3. Сөйләшүләр барышында килешү шартлары буенча килешүгә ирешелгән очракта, эшче төркем килешү төзү инициаторына киңәшмәдә катнашучыларның барысы да имзалаган килешүнең килештерелгән шартларын үз эченә алган беркетмәне җибәрә.

4. Сөйләшүләр барышында яклар килешү шартлары буенча килешүгә ирешмәгән очракта, концессия килешүен төзү инициаторы “Яңа Кенәр коммуналь хезмәтләре” ҖЧҖ белән уртак киңәшмәләр рәвешендә сөйләшүләр үткәрү вакытын 3 айга озайтырга.

5. Сөйләшүләр барышында яклар килешү шартлары буенча килешүгә ирешмәгән очракта, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты “Концессия килешүләре турында” 2005 елның 21 июлендәге 115-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясындагы 4.6 өлешенең 9 пункты нигезендә сөйләшүләр уздырылган көннән алып 10 эш көне эчендә имзаланган беркетмә нигезендә килешү төзү мөмкин түгеллеге турында Карар кабул итә, баш тарту нигезен күрсәтә һәм мондый карарның күчермәсен Килешү төзү инициаторына җибәрә.

6. Килешү төзү инициаторы сөйләшүләр уздыру нәтиҗәләре буенча беркетмә алганнан соң, сөйләшүләр нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарларны исәпкә алып, Килешү проектына үзгәрешләр кертә һәм Килешү проектын беркетмә алынган көннән 10 (ун) эш көненнән дә артмаган срокта эшче төркемгә җибәрә.

7. Эш төркеме кертелгән үзгәрешләр белән Килешү проектын алган көннән алып 3 (өч) эш көне эчендә тапшырылган документларны карый һәм килешү проектын килештерү мөмкинлеге турында йә аны килештерү мөмкин түгеллеге турында карар кабул итә. Эшче төркемнең барлык карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Эш төркеме Килешү проектын килештерү мөмкинлеге турында карар кабул иткән очракта, күрсәтелгән карар Арча муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрелә.

8. Арча муниципаль районы башкарма комитеты эшче төркем беркетмәсе кергән көннән алып 3 (өч) эш көне эчендә Килешү проектын килештерү һәм Килешү төзү турында йә Килешү проектын килештермәү турында тәкъдим кабул итү турында карар кабул итә.

**Арча муниципаль районы башкарма**
**комитеты карарына 2 нче кушымта**
**«10» апреля 2026 ел №293**

“Яңа Кенәр коммуналь хезмәтләре” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте белән уртак киңәшмәләр рәвешендә сөйләшүләр алып баруга вәкаләтле эшче төркем составы

| № | ФИО | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Галимуллин Ильшат Әхәт улы | Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары |
| 2. | Сираҗиев Илһам Гаптельнур улы | Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе |
| 3. | Хәсәнов Ильнур Мәхмүт улы | Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе |
| 4 | Дәүләтбаева Гөлшат Миннефар кызы | Башкарма комитетның инфраструктура үсеше бүлегенең ТКХ, энергетика һәм элемтә секторы баш белгече |
| 5 | Гайфуллин Әгъзәм Әдехәм улы | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе |
| 6 | Хайруллина Сөмбелә Адил кызы | Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре |